**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15 января 2016 г

г.Казань

**№** 01-02/10

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2002 елның 24 декабрендәге 01-01/19 номерлы боерыгы белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен куллану турында аңлатмаларга үзгәреш кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2002 елның 24 декабрендәге 01-01/19 номерлы боерыгы белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен куллану турында аңлатмаларга, аларны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының норматив хокукый актларны теркәү һәм эшчәнлекне хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы (Э.И. Слепнева) әлеге боерыкка кул куелганнан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча Аңлатмаларны республика башкарма хакимият органнарына җибәрергә.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И. Заһидуллинга йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
2009 елның 31 мартындагы
01-02/70 номерлы боерыгы
белән расланган
(Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
2016 елның 15
гыйнварындагы 01-02/10
номерлы боерыгы
редакциясендә)

**Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен куллану турында аңлатма**

Әлеге Аңлатмалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 2002 елның 18 июлендәге 426 номерлы карарының (алга таба - Кагыйдәләр) 1 пункты нигезендә, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү, республика башкарма хакимияте органнары чыгара торган норматив хокукый актларның федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен хокукый җайга салуны һәм тикшереп торуны камилләштерү максатларында эшләнде.

I. Республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актлар әзерләү

1.1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән, шулай ук республика башкарма хакимият органнары инициативасы буенча аларның компетенциясе кысаларында чыгарыла.

1.2. Әлеге Аңлатмаларда норматив хокукый акт төшенчәсе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 18 июлендәге 427 номерлы карары (алга таба - Тәртип) белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкын формалаштыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актлар тапшыру тәртибендә билгеләнгән мәгънәдә кулланыла:

норматив хокукый акт - билгесез затлар даирәсе өчен мәҗбүри булган, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм учреждениеләр, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре тарафыннан күп тапкыр куллануга һәм үтәлүгә исәпләнгән хокукый нормаларны (тәртип кагыйдәләрен) билгеләүче язма рәсми документ.

Бер үк вакытта «Россия Федерациясе Конституция судына мөрәҗәгать итү турында» 1996 елның 11 ноябрендәге 781-II ДС номерлы Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы карарында булган норматив хокукый актның билгеләмәсен дә исәпкә алырга кирәк, аның нигезендә норматив хокукый акт - хокук чыгару органы тарафыннан билгеләнгән рәвештә кабул ителгән һәм хокукый нормаларны билгеләү, үзгәртү яисә юкка чыгаруга юнәлдерелгән язма документ. Үз чиратында, хокукый норма дигәндә даими яки вакытлыча характердагы күп тапкыр куллануга исәпләнгән гомуми мәҗбүри дәүләт күрсәтмәсен аңларга кирәк.

1.3. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 43 статьясындагы 1 өлеше нигезендә республика башкарма хакимият органнары үз компетенциясе чикләрендә норматив хокукый актлар чыгара, республика башкарма хакимияте органына караган барлык

оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр тарафыннан үтәлергә тиешле кагыйдәләрне, нигезләмәләрне, регламентларны, инструкцияләрне, методик документларны раслый. Республика башкарма хакимияте органы чыгара торган хокукый актлар төрләре бу орган турында нигезләмә белән билгеләнә.

1.4. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан норматив хокукый актлар проектларын эшләү республика башкарма хакимият органнары тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектларын юридик-техник рәсмиләштерү буенча Методик тәкъдимнәрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла, ул Юстиция министрлыгының 2015 елның 10 ноябрендәге 01-02/759 номерлы боерыгы белән расланган.

1.5. Норматив хокукый акт проекты республика башкарма хакимияте органында билгеләнгән тәртиптә хокукый экспертиза узарга һәм "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә коррупциягә каршы экспертиза узарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасында, законнарда, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнелә торган, башкарма хакимиятнең бу органнары каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында" 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карарында билгеләнгән очракларда республика башкарма хакимияте органының иҗтимагый советында алдан фикер алышуга җибәрелергә тиеш.

1.6. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый акт проекты «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә җайга салу йогынтысын бәяләүгә тиеш. Норматив хокукый акт проектын бәяләүне уздыру турындагы мәгълүмат норматив хокукый актка карата белешмәдә чагыла һәм вәкаләтле орган бәяләмәсе актны дәүләт теркәвенә алу белән бер үк вакытта тапшырыла.

1.7. «Һөнәр берлекләре, аларның хокуклары һәм эшчәнлек гарантияләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 10-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы таләпләре нигезендә хезмәткәрләрнең социаль-хезмәт хокукларына кагылышлы норматив хокукый актлар проектлары тармак профсоюз органы фикерен исәпкә алып, республика башкарма хакимият органнары тарафыннан карала һәм кабул ителә. Тармак профсоюз органы әйткән фикер каралырга тиеш. Әгәр ул кире кагыла икән, профсоюзга бу хакта дәлилләнгән бәяләмә җибәрелергә тиеш.

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләре нигезендә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан раслана торган норматив-техник һәм инструктив-методик документлар проектлары әлеге Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үткәрелә торган төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экологик экспертиза объектлары булып тора.

1.8. Норматив хокукый акт берничә республика башкарма хакимият органнары белән берлектә яисә аларның берсе белән килешенеп басылып чыгарга мөмкин.

Республика башкарма хакимиятенең башка органнары белән берлектә чыгарылган норматив хокукый акт актны беренче булып чыгарган орган тарафыннан билгеләнә торган бердәм датага һәм тиешле номерларга ия булырга тиеш.

Башкарма хакимиятнең башка органнары белән берлектә яисә алар белән килешенеп чыгарылган норматив хокукый актлар әлеге республика башкарма хакимият органнары белән килешенеп үзгәрә яки үз көчен югалткан дип таныла.

1.9. Әгәр норматив хокукый актны әзерләгәндә элек чыгарылган норматив хокукый актларга сизелерлек үзгәрешләр кертү кирәклеге яки бер үк мәсьәлә буенча берничә актның булуы ачыкланган булса, аларны тәртипкә салу максатларында яңа бердәм акт эшләнә. Мондый акт проектына яңа, шулай ук элек чыгарылган актларда булган актуаль норматив күрсәтмәләр кертелә.

1.10. Республика башкарма хакимият органының норматив хокукый акты белән мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен нигез булган закон һәм башка норматив хокукый актларга сылтама ясаганда, мондый актларның барлык реквизитларын күрсәтергә кирәк.

Дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырыла торган норматив хокукый актта республика башкарма хакимият органының дәүләт теркәвенә алынмаган норматив хокукый актына сылтама ярамый.

1.11. Республика башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында (алга таба - Министрлык) теркәлгән норматив хокукый акты үз көчен югалткан дип танылган, шулай ук аңа үзгәрешләр кертелгән очракта, тиешле акт билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырыла.

1.12. Норматив хокукый актка кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, кагыйдә буларак, төп документ чыгарылган төрдәге норматив хокукый акт белән рәсмиләштерелә, акт республика башкарма хакимият органы турындагы нигезләмәдә каралмаган рәвештә басылып чыккан очраклардан тыш. Бу очракта норматив хокукый актка үзгәрешләр боерык белән кертелә.

## I. Норматив хокукый актларны дәүләт теркәвенә алу

2.1. Министрлыкта Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары дәүләт теркәвенә алынырга тиеш:

гражданнар, сәяси, социаль-икътисадый һәм башка хокукларга, кеше һәм гражданның ирекләренә һәм бурычларына, аларны гамәлгә ашыру гарантияләренә, Россия Федерациясе Конституциясендә, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм башка закон актларында беркетелгән хокукый нормаларга, шулай ук хокукларны, ирекләрне һәм бурычларны гамәлгә ашыру механизмына кагылышлы хокукый нормаларны үз эченә алган;

оешмаларның хокукый статусын билгели торган - органнар (мәсәлән, территориаль), тиешле республика башкарма хакимияте органнары карамагындагы оешмалар турында типлаштырылган, үрнәк нигезләмәләр (уставлар);

ведомствоара характердагы, ягъни республика башкарма хакимиятенең башка органнары һәм (яки) республика башкарма хакимият органы системасына кермәгән оешмалар өчен мәҗбүри булган, (норматив хокукый актны бергә раслаган ике яки аннан күбрәк республика башкарма органы) республика башкарма хакимияте органнары системасына кермәгән хокукый нормалар булган.

Шул ук вакытта дәүләт теркәвенә югарыда күрсәтелгән билгеләрнең берсе булган норматив хокукый актлар да, берничә билге белән булганы да җибәрелә.

2.2. Норматив хокукый актлар, гамәлдә булу срогына бәйсез рәвештә, дәүләт теркәвенә алынырга тиеш - даими гамәлдәгеләр, шулай ук вакытлы (билгеле бер вакытка кабул ителгән, әмма күп тапкыр куллануга исәпләнгән), шул исәптән дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр яки конфиденциаль характердагы белешмәләр булган актлар.

2.3. Дәүләт теркәвенә кертелергә тиеш түгел:

шәхси хокукый актлар: (вазыйфага билгеләп кую яки вазыйфадан азат итү, бүләкләү яки түләттерү турында һ. б.);

аларның гамәлдә булуы бер тапкыр кулланыла;

гамәлдә булу вакыты чыккан;

оператив-боеру характерындагы (бер тапкыр бирелгән йөкләмәләр);

югарыдагы дәүләт органнарының карарлары республика башкарма хакимият органы системасы органнары һәм оешмалары игътибарына җиткерелә торган актлар;

югарыдагы органнар карарларын яисә республика башкарма хакимият органнарының үз карарларын үтәүне оештыруга юнәлдерелгән һәм яңа хокукый нормалар булмаган актлар;

техник актлар (ГОСТлар, Сниплар, Санпиннар, тариф-квалификация белешмәләре, статистик күзәтү формалары һ. б.), әгәр алар хокукый нормаларда булмаса;

тәкъдим итү характерындагы актлар.

2.4. Норматив хокукый актларның әлеге Аңлатмаларның 2.1 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килүендә шик туган очракта, мондый актлар билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш. Дәүләт теркәвенә алу зарурлыгы турындагы мәсьәләне ахыргы хәл итү Министрлык тарафыннан хокукый экспертиза үткәргәннән соң кабул ителә.

2.5. Норматив хокукый актлар дәүләт теркәвенә алу өчен алар имзаланганнан соң өч эш көне эчендә, тиешле республика башкарма хакимият органының озату хаты белән тапшырыла. Норматив хокукый акт белән бер үк вакытта тапшырыла торган документлар һәм белешмәләр исемлеге Кагыйдәләрнең 2.4 пункты белән билгеләнгән.

2.6. Норматив хокукый актның күчермәләре республика башкарма хакимият органының мөһере (герблы түгел) һәм республика башкарма хакимият органы хезмәткәре имзасы (вазыйфага карата таләпләрне билгеләмичә) белән расланырга тиеш.

Норматив хокукый актның күчермәләре түбәндәгечә бүленә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы редакциясенә бастырып чыгару өчен;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларының федераль регистрына кертү өчен.

2.7. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу Министрлык тарафыннан эш көннәрендә санала торган, озату хатын теркәү датасыннан алып исәпләнә торган 15 көн эчендә башкарыла. Озату хатын теркәү документларны кәгазьдә тапшырганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.8. Норматив хокукый актларны дәүләт теркәвенә алу алдыннан хокукый экспертиза, коррупциягә каршы экспертиза һәм хокукый техника кагыйдәләренә туры килү-килмәүгә анализ ясала.

2.9. Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен законнар җыелмасына каршы килә торган нигезләмәләрнең булуы, актны республика башкарма хакимият органына бирелгән вәкаләтләрдән читтә бастырып чыгару, юридик техника таләпләрен үтәмәү һәм норматив хокукый актларны дәүләт теркәвенә тапшыруның билгеләнгән тәртибен үтәмәү, шул исәптән Кагыйдәләрнең 2.4 пунктында каралган документларның һәм белешмәләрнең булмавы, шулай ук Татарстан Республикасы Прокуратурасының тискәре бәяләмәсе тора.

2.10. Татарстан Республикасы Прокуратурасы һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы арасында норма иҗат итү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда хезмәттәшлек турында 2011 елның 30 июлендәге килешү нигезендә, дәүләт теркәвенә тапшырылган, Министрлыкның уңай бәяләмәсен алган норматив хокукый актлар, мондый бәяләмә чыгарылган көнне, Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелә. Дәүләт теркәве Татарстан Республикасы Прокуратурасының уңай бәяләмәсен алганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.11. Дәүләт теркәвенә алу төп нөсхәдә һәм норматив хокукый актның һәр күчермәсен дәүләт теркәвенә алу (теркәү штампы) турында билге кую һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт реестрына кертү белән раслана.

2.12. Әгәр Татарстан Республикасы Прокуратурасы тарафыннан тискәре бәяләмә чыгарылган очракта, норматив хокукый акт актны чыгарган республика башкарма хакимият органына, мондый бәяләмәнең күчермәсен кушып, Министрлык тарафыннан бәяләмә алынган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча кире кайтарыла.

2.13. Дәүләт теркәвенә алынудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, республика башкарма хакимият органына норматив хокукый актның төп нөсхәсе, шулай ук аның күчермәләре, Министрлыкта кала торган берсеннән тыш, кире кайтарыла.

2.14. Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу белән бәйле документлар, шул исәптән актның дәүләт теркәвенә алынганнан соң төп нөсхәсе, шулай ук дәүләт теркәвенә алынудан баш тарткан очракта күчермәләре булган төп нөсхә Министрлыкта республика башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә имза куйдырып, кулларына бирелә.

### III.Норматив хокукый актларны бастырып чыгару республика башкарма хакимият органнары

3.1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, рәсми бастырып чыгару аларның үз көченә керүе шарты булып тора һәм Министрлыкта дәүләт теркәвенә алынганнан соң гамәлгә ашырыла.

Республика башкарма хакимият органнарының кагыйдәләрдә теркәлмәгән һәм билгеләнгән тәртиптә бастырылмаган норматив хокукый актлар кулланылырга тиеш түгел.

3.2. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт теркәвенә алынган көннән соң 10 көн эчендә басылып чыгарга тиеш. Актны министрлыкка тапшыруның билгеләнгән срогын үтәү өчен норматив хокукый акт чыгарган республика башкарма хакимият органы җаваплы.

3.3. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару чыганагы булып түбәндәге массакүләм мәгълүмат чаралары тора:

«Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы;

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (PRAVO.TATARSTA№. RU).

3.4. Республика башкарма хакимият органы тарафыннан теркәлгән норматив хокукый актны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында рәсми бастырып чыгару турында карар кабул ителгән очракта, норматив хокукый актның электрон күчермәсе министрлык газеталары редакциясенә PDF форматында әзерләнә һәм җибәрелә. Норматив хокукый актларны бастырып чыгару чыгымнарын газеталар редакцияләренә акт чыгарган республика башкарма хакимият органы түли. Норматив хокукый актны бастырып чыгарганда, берничә республика башкарма хакимият органнары белән берлектә чыгымнар әлеге органнар тарафыннан килештерү буенча түләнә.

Моның белән бергә, республика башкарма хакимият органының Министрлык белән килештерү буенча,  бюджет акчалары чыгымнарын киметү максатларында һәм печатьтә нинди кушымта китерелмәвен һәм аның белән нинди ресурста танышу мөмкинлеген күрсәтеп (мәсәлән, республика башкарма хакимият органының рәсми сайты), норматив хокукый актларга өстәмә яки тулыландыру характердагы (таблицалар, графиклар, карта, схемалар), кушымталар бастырып чыгарылмаска мөмкин.

3.5. Норматив хокукый актны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTA№.RU) бастырып чыгару турында карар кабул ителгән очракта, теркәлү штампы белән актның күчермәсе, актны бастырып чыгарган орган тарафыннан рус һәм татар телләрендә электрон рәвештә PDF форматында Министрлыкка җибәрелә. Норматив хокукый акт текстының электрон күчермәсе эчтәлегенең охшашлыгы өчен норматив хокукый актны чыгарган республика башкарма хакимияте органы җавап бирә. Норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру түләүсез гамәлгә ашырылганга күрә, норматив хокукый актлар тулы күләмдә (аларның характерына бәйсез рәвештә, барлык кушымталар белән) урнаштырыла.